ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер, Арский
муниципальный район, 422031

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы,
Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**24 декабрь 2021 ел** **№43**

**«Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
гражданнардан үзара салым
акчаларын җыю тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Яңа Кенәр авыл җирлеге советының 2021 елның 21 октябрендәге 48 номерлы карары, 08.11.2021 №1, 08.11.2021 №2, 09.11.2021 №3, 09.11.2021 №4, 10.11.2021 №5, 12.11.2021 №6, 15.11.2021 №7, 16.11.2021 №8, 16.11.2021 №9, 16.11.2021 №10 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Яңа Кенәр авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кенәр авылы, Совет урамы, 10 нчы йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Сөрде авылы, Совет урамы, 48 нче йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Шурабаш авылы, Гагарин урамы, 17 нче йорт.

3. «Яңа Кенәр авыл җирлеге» Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге №42 «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яна Кенәр авыл җирлеге башлыгы Гайфуллин Ә.Ә.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы Яңа
Кенәр авыл җирлеге Башкарма
комитетының
24 декабрь 2021 ел. №43
карарына 1 нче кушымта

**«Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасы 2022 елның 16 февраленә кадәр «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләре нинди булуга карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Аерым категория гражданнар:

а) 1 төркем инвалидлар,

б) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар,

в) балачактан инвалидлар,

г) хәрби хәрәкәтләр ветераннары,

д) Чернобыль АЭС авариясен бетерүдә катнашучылар өчен түләү күләме җирле җыеннарда билгеләнгән суммадан 50 (илле) процент тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрү булганда булганда

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында гражданнарга хәбәр итү хәбәрнамә бланкын Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куйдырып шәхсән бирү яисә почта аша җибәрү юлы белән житкерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан җыелган акчалар «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7.Түләүләр физик зэтлар поручениесе буенча почта аша исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешма аша күчерелә.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып касса керем ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы Яңа
Кенәр авыл җирлеге Башкарма
комитетының
24 декабрь 2021 ел, №43
карарына 2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № ______________

«Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча
бер мәртәбә түләү турында

Түләүченең ф. и. а.и.______________________________________________
Адресы:__________________________________________
________________________________________________нигезендә
Сезгә 2022 елның 21 февраленә кадәр төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга ______________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча:
РОССИЯ БАНКЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МБ БҮЛЕГЕ// ТАТАРСТАН БУЕНЧА УФК Казан ш.
Алучы банкы БИК ___019205400
Алучы сч. № 03100643000001 1100
Алучы сч. № 40102810445370079 банк хисабы
ИНН 1609009548
КПП _____160901001
КБК 89511714030 13 0000 150
ОКТМО 92612151
Түләү билгеләнеше- гражданнарның шәһәр җирлекләре бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары

бер тапкыр түләнә торган түләү кертергә кирәк.

Җитәкче _______________ ____________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)
М. у.
- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Түләүченең ф. и. а.и.________________________________________
Адресы: ________________________________________________
______________сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган үзара салымны «Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына кертү турында ___ номерлы хәбәрне (хәбәрнамә) алдым:

«___» __________ 20__ ел ___________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)
*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзек корешок тутырыла һәм ______________ җирлеге башкарма комитетында кала.*